**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «07» ноябреннән № 271

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында 2024 елга торак хезмәтләренә тарифларны раслау турында» 2023 елның 20 декабрендәге 278 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең 2006 елның 13 нче августындагы «Күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йорттагы гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча тиешле сыйфатта булмаган һәм (яки) билгеләнгән вакыттан узып киткән өзеклекләр белән хезмәт күрсәткән очракта торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында»гы 491 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма коомитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында 2024 елга торак хезмәтләренә тарифларны раслау турында» 2023 елның 20 декабрендәге 278 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымта исемен түбәндәге редакциядә бирергә:

«Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучыларны, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яисә) гомуми җыелышта 2024 елга торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү

турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләрен карап тоткан өчен күләм».

1.2. Кушымтаның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7 | Агымдагы ремонт һәм йорт эчендәге газ челтәрләрен карап тоту, шул исәптән:<br>- күпфатирлы йортларда йорт эчендәге газ җиһазлары системаларын;<br>- күпфатирлы йортларда мичләрне, каминнарны һәм учакларны (төтенлекләрне) тиешле тәртиптә тоту максатларында башкарыла торган эшләр | кв. м. аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 0,31<br><br>1,19 | 0,31<br><br>1,19 |

1.3. Кушымтаны түбәндәге эчтәлектәге 10 пункт белән тулыландырырга:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10 | Эчтәге газ җиһазларын техник диагностикалау (түләүне исәпләү диагностикалауны үткәрү вакыты башланганчы 12 ай эчендә башкарыла) | кв. м. аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | - | 1,0 |

1.4. Кушымтаны түбәндәге эчтәлектәге 11 пункт белән тулыландырырга:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 11 | Күпфатирлы йортларның вентиляция һәм төтен каналларын тикшерү (карау) һәм чистарту: | кв. м. аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | - | 0,79 |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/ novosheshminsk.tatarstan.ru/ һәм «Яңа Чишмә хәбәрләре» район газетасында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты / Исполнительный комитет Новошешминского муниципального района Республики Татарстан, ИНН 1631003397, ОГРН 1051660041740